Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының унынчы утырышы

КАРАР

25 май, 2018 ел № 14

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 24 номерлы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып бердәй датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 24 номерлы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

2 пунктның 3 пунктындагы 4 абзацында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча,2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова